МИНИСТЕРСТВО ЗЕМЕЛЬНЫХ И ИМУЩЕСТВЕННЫХ ОТНОШЕНИЙ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ҖИР ҺӘМ МӨЛКӘТ МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ МИНИСТРЛЫГЫ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

**16.06.2017** **г. Казань** **№ № 1337-р**

**«Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан торак пунктлары җирләре (Казан шәһәре торак пункты җирләреннән тыш) составындагы җир кишәрлекләренең дәүләт кадастр бәясен билгеләү нәтиҗәләрен раслау турында» Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының 2015 ел, 25 ноябрь, 2846-р карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Аерым кадастр кварталларында җир кишәрлеген куллану төрләре буенча җир кишәрлекләренең кадастр бәясенең уртача мәйданы буенча чагыштырмача күрсәткече булмауда чагылган техник хатаны бетерү максатыннан:

1. “Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан торак пунктлары җирләре (Казан шәһәре торак пункты җирләре искәрмә булып тора) составындагы җир кишәрлекләренең дәүләт кадастр бәясен билгеләү нәтиҗәләрен раслау турында” Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының 2015 ел, 25 ноябрь, 2846-р карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан торак пунктлары җирләре (Казан шәһәре торак пункты җирләреннән тыш) составындагы җир кишәрлекләренең дәүләт кадастр бәясен билгеләү нәтиҗәләренә үзгәреш кертеп, «II. Җир

кишәрлекләренең кадастр бәясенең уртача мәйданы буенча чагыштырмача күрсәткече, кв.метрга сумнарда» Кушымтасын беркетелгән редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының www.mzio.tatarstan.ru адресындагы рәсми сайтына урнаштырырга.

**Министр** **А.К.Хамаев**